РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» 02 2019 г. №151

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының кешеләр үлеме дәрәҗәсе буенча ведомствоара комиссиясен һәм аның составын раслау турында

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы халкының үлеме сәбәпләрен мониторинглауны оештыру, өйрәнү һәм аны киметүгә юнәлтелгән нәтиҗәле чараларны үз вакытында күрү максатларында карар итә:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

1.1 Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында кешеләр үлеме дәрәҗәсе буенча ведомствоара комиссия эше турында Нигезләмәне (1 нче кушымта);

1.2 Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында кешеләрүлеме дәрәҗәсе буенча ведомствоара комиссия составын (2 нче кушымта);

2. Комиссия эшчәнлеген контрольдә тотуны ТР Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче С.П. Самонина

Д.Т. Волкова
Тел. 2-73-11

Кушымта №1
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Башкарма комитеты җитәкчесе Карары
белән расланды
№_____ _________ 2019 ел

# ТР ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КЕШЕЛӘР ҮЛЕМЕ ДӘРӘҖӘСЕ БУЕНЧА ВЕДОМСТВОАРА КОМИССИЯСЕ ЭШЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Үлем дәрәҗәсе буенча комиссия Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән төзелә .

1. Комиссиягә ТР Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары җитәкчелек итә.

2. Комиссия составына сәламәтлек саклау оешмаларының җитәкчеләре һәм белгечләре кертелә.

3. Комиссия карарлары үтәү очен мәҗбүри булып тора.

## 2. Комиссиянең бурычлары

1. ТР Ютазы муниципаль районы халкының үлеме сәбәпләренә анализ үткәрү.

2. Халык үлеме дәрәҗәсен тотрыкландыруга һәм киметүгә, медицина ярдәме сыйфатын яхшыртуга һәм оештыруга юнәлдерелгән ашыгыч һәм озак вакытлы идарә карарларын эшләү һәм кабул итү.

## 3. Хокуклар һәм бурычлар

Комиссия хокуклы:

1.Район оешмалары һәм учреждениеләре тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле карарлар чыгарырга.

2. Учреждениеләр җитәкчеләреннән комиссия эше өчен мәгълүмат соратып алырга.

Комиссия бурычлы:

1. Халыкның, шул исәптән хезмәткә яраклы яшьтә үлучеләр буенча күрсәткечләргә динамикалы анализ ясарга.

2. Район халкына медицина ярдәмен оештыру һәм күрсәтү буенча анализ үткәрергә.

## 4. Комиссия эшен оештыру

1. Комиссия утырышлары мөһим булганда уздырылырга тиеш, әмма ярты елга бер тапкырдан да ким түгел.

2. Комиссия утырышы төп составның 2/3сеннән дә ким булмаган өлеше катнашканда, тулы хокуклы санала.

3. Комиссия секретаре комиссия утырышы билгеләнгән көнгә кадәр 7 көн кала комиссия Рәисенә каралучы мәсьәлә буенча халык үлеме дәрәҗәсен анализлау буенча статистик материал тәкъдим итә.

4. Комиссиянең чираттан тыш утырышы Комиссия әгъзасы тарафыннан Комиссия рәисенә нигезле тәкъдимнәр кертү юлы белән тәкъдим ителергә мөмкин.

5. Комиссиянең чираттан тыш утырышын үткәрү турындагы карар Комиссия рәисе тарафыннан кабул ителә.

6. Комиссия утырышлары төп состав белән дә, ачык утырышлар рәвешендә дә үткәрелә ала.

7. Комиссия утырышлары Урыссу үзәк район хастаханәсендә дә, шулай ук ТР Ютазы муниципаль районының Башкарма комитетында һәм район Советында да үткәрелергә мөмкин .

Кушымта №2
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты Карарына
№___ “___” ________ 2019 ел

## ТР ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КЕШЕЛӘР ҮЛЕМЕ ДӘРӘҖӘСЕ БУЕНЧА ВЕДОМСТВОАРА КОМИССИЯСЕ СОСТАВЫ

Волкова Д.Т. - ТР Ютазы муниципал районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль сораулар буенча урынбасары – рәис *(килешү буенча);*

Шакирова С.З. - Урыссу үзәк район хастаханәсенең баш табибы *(килешү буенча);*

Рахмаева М. А. - Урыссу үзәк район хастаханәсе оештыру-методик бүлмәсенең өлкән фельдшеры – сәркатип *(килешү буенча);*

Комиссия әгъзалары:

Хисамова С.Ә. - ТР Ютазы муниципаль районы Урыссу үзәк район хастаханәсенең баш табибы урынбасары *(килешү буенча);*

Фәррахова З.М. - ТР Ютазы муниципаль районы ЗАГС бүлеге начальнигы *(килешү буенча);*

Миңневәлиев Н.Н. - ТР Ютазы муниципаль районы “Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ директоры *(килешү буенча).*

Сибәгатов М.В. - ТР Ютазы муниципаль районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге начальнигы *(килешү буенча);*

Рәшитова З.Ә. – ТР Ютазы муниципаль районында социаль яклау бүлеге начальнигы *(килешү буенча).*